ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2024 №6

Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет төзү турында

«Балаларның һәм яшьләрнең Россия хәрәкәте турында» 2022 елның 14 июлендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе президиумының 2023 елның 24 августындагы ПР-94-2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы  совет төзергә.

2. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм

яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы  совет составын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет секретаре, Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте җирле бүлекчәсе җитәкчесенә Алабуга муниципаль районы Башлыгының  штаттан тыш ярдәмчесе статусын бирергә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район Башлыгы                                                                                Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының карарына
1 нче кушымта
15.02.2024
№6

**Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- Балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагыйдәүләт хәрәкәте (алга таба Хәрәкәт) – илнең барлык балалар һәм яшьләр оешмаларын һәм хәрәкәтләрен берләштерүче, балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләрендә дәүләт сәясәтен алып баруга ярдәм итүне, балаларны тәрбияләүгә, һөнәри ориентациягә, үз-үзеңне тормышка ашыруга, һәрьяклап үсешкә һәм ял оештыруга ярдәм итүне максат итеп куйган ирекле, үз-үзен идарә итүче гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте;

Хәрәкәтнең структур бүлекчәләре түбәндәгеләр:

- Россия Федерациясенең һәр субъектында төзелә торган Хәрәкәтнең төбәк бүлекчәләре;
- муниципаль берәмлекләрдә төзелә торган Хәрәкәтнең җирле бүлекләре;
- Хәрәкәтнең беренчел бүлекчәләре, гомуми белем бирү оешмаларында, һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү оешмаларында, шулай ук яшьләр сәясәте инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларда, мәдәният һәм спорт өлкәсендәге оешмаларда, балалар һәм яшьләр белән эш алып баручы башка оешмаларда булдырыла. Беренчел бүлекләр шулай ук ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда оештырылырга мөмкин.

Хәрәкәтнең төбәк, җирле һәм беренчел бүлекчәләре Хәрәкәт уставы һәм Хәрәкәтнең эчке документларында каралган тәртиптә төзелә һәм эшчәнлек алып бара.

- Тәрбия программасы – тәрбия эшчәнлегенең эчтәлеген һәм формаларын ачучы документ;

Хәрәкәтнең тәрбия эше программасы – Хәрәкәт эшчәнлегенең максатларына ирешүне тәэмин итүче төп документ. Программаны гамәлгә ашыруда педагогик һәм башка хезмәткәрләр, Хәрәкәт остазлары Хәрәкәт коллективында катнашучылары, беренчел җирле, төбәк бүлекчәләре катнаша.

1.2. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет (алга таба – тәрбия эше буенча Совет) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы даими эшләүче киңәшмә органы булып тора һәм ул түбәндәге максатларны үз эченә ала:

- Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының, җирле үзидарә органнарының килештерелгән эшчәнлеген тәэмин итү, алар карамагында мәгариф, яшьләр һәм гаилә сәясәте, сәламәтлек саклау, социаль сәясәт, физик культура һәм спорт, Алабуга муниципаль районы территориясендә эшләүче хокук тәртибен, мәдәният, туризм, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында тәрбия эше мәсьәләләре буенча башка кызыксынучы оешмаларның килештерелгән эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының, җирле үзидарә органнарының килештерелгән эшчәнлеген тәэмин итү, алар карамагында мәгариф, яшьләр һәм гаилә сәясәте, сәламәтлек саклау, социаль сәясәт, физик культура һәм спорт, иминлек һәм хокук тәртибе, мәдәният, туризм, муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә эшләүче иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында тәрбия эше мәсьәләләре буенча башка кызыксынучы оешмаларның килешенгән эшчәнлеген тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Хәрәкәтенең җирле бүлекчәсенә балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

- мәгариф оешмаларында тәрбия эше программаларын, балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең тәрбияви эш программаларын гамәлгә ашыруда ярдәм итү.

1.3. Үз эшчәнлегендә тәрбия эше буенча совет Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциоя законнары, Россия Федерациясенең

федераль законнары, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

## 2. Тәрбия эше советының бурычлары

2.1. Мәгариф, яшьләр һәм гаилә сәясәте, сәламәтлек саклау, социаль сәясәт, физик культура һәм спорт, куркынычсызлык һәм хокук тәртибен саклау, мәдәният, туризм, Алабуга муниципаль районында Хәрәкәтне үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү, бүлекчәләр белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

2.2. Оешмаларны җәлеп итеп, балалар һәм яшьләргә һөнәри юнәлеш бирүне гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

2.3. Перспективалы муниципаль балалар һәм яшьләр инициативаларын һәм проектларын мониторинглау һәм аларга максатчан ярдәм күрсәтү буенча тәкъдимнәр әзерләү, шул исәптән, җирле бюджет акчалары хисабына;

2.4. Балалар һәм яшьләр белән эшләүнең алымнарын камилләштерү максатыннан остазлык институтларын үстерүгә ярдәм итү.

## 3. Тәрбия эше советының хокуклары

3.1. Үз бурычларын үтәү максатларында тәрбия эше буенча совет түбәндәгеләргә хокуклы:

- җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрдән һәм оешмалардан совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;
- үз утырышларына Алабуга муниципаль районы органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм башка вазифаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында тәрбия эшен оештыруда кызыксынучы оешмалар һәм башка затларны Хәрәкәтенең төбәк бүлеген үстерүдә җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен чакырырга;
- тәрбия эше буенча совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча эшче төркемнәр төзү.

## 4. Тәрбия эше буенча советны формалаштыру тәртибе

4.1. Тәрбия эше буенча совет составына тәрбия эше буенча советның рәиес, рәис урынбасары, секретаре һәм аның иҗтимагый башлангычларда катнаша торган башка әгъзалары керә.

4.2. Тәрбия эшләре буенча совет рәисе булып Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы тора.

4.3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хәрәкәтенең җирле бүлеге советы рәисе тәрбия эше буенча совет секретаре булып тора.

4.4. Тәрбия эшләре буенча совет рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4.5. Тәрбия эше буенча совет составына килешү буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының, яшьләр сәясәтен һәм спортны үстерү секторы мөдирләре, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы керә.

4.6. Тәрбия эше буенча совет составы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

## 5. Тәрбия эше буенча советның эш тәртибе.

5.1. Тәрбия эше буенча совет эше белән совет рәисе җитәкчелек ит.ә

5.2. Тәрбия эше буенча совет эше аның утырышларында расланган планнарга ярашлы рәвештә башкарыла.

5.3. Тәрбия эше буенча Совет утырышлары кирәк булган саен турыдан-туры, читтән торып яисә турыдан-туры-читтән торып уку формаларында уздырыла, ләкин елына ике тапкырдан да ким булмаска тиеш.

5.4. Үз вәкаләтләре кысаларында тәрбия эше буенча совет рәисе:

а) тәрбия эше буенча совет эше белән җитәкчелек итә, исемлекне, срокларны һәм мәсьәләләрне утырышларда карау тәртибен билгели;

б) утырышларны уздыру көнен, датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

в) утырышлар беркетмәләрен һәм советның тәрбия эше буенча башка документларын имзалый.

5.5. Тәрбия эшләре советы рәисе урынбасары:

а) тәрбия эше (командировка, отпуск) советы рәисе булмаганда, тәрбия эше буенча совет рәисе вазифаларын башкара.

б) агымдагы мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

5.6. Тәрбия эшләре советы секретаре:

а) тәрбия эше буенча совет утырышларында шәхсән яисә читтән торып катнаша;

б) ) тәрбия эше буенча совет әгъзаларына утырыш уздырылачак урын, дата, вакыт турында утырыш уздырылачак көнгә кадәр кимендә биш календарь көн кала хәбәр итә, көн тәртибен һәм утырышка материаллар җибәрә;

в) утырышлар беркетмәләрен һәм советның тәрбия эше буенча башка документларын әзерли.

5.7. Тәрбия эше буенча совет әгъзалары:

а) тәрбия эше буенча совет утырышларында шәхсән яисә читтән торып катнашалар;

б) тәрбия эше буенча совет компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне тикшерүгә чыгаралар;

в) в) тәрбия эше буенча совет карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чаралар үткәрәләр.

5.8. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы булып санала.

5.9. Тәрбия эше буенча советның карары тәрбия эше буенча совет әгъзаларыннан язмача сораштыру үткәрү юлы белән читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

Читтән торып тавыш бирү үткәрү турындагы хәбәр, тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәлә буенча материаллар кушымтасы белән, читтән торып тавыш бирү йомгаклары ясалган көнгә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, тәрбия эше буенча совет секретаре тәрбия эше буенча совет әгъзаларына аны алуны тәэмин итүче теләсә нинди ысул белән (шул исәптән почта, факсимиль элемтә һәм электрон почта аша) җибәрелә. Хәбәрдә тәрбия эше буенча совет әгъзасының каралган мәсьәлә буенча үз фикерен язма формада тапшыру вакыты тәмамлану датасы күрсәтелә.

Тәрбия эше буенча совет әгъзалары читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләрен ясау датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, тәрбия эше буенча совет секретаре исеменә тавыш бирү мәсьәләләре буенча үз фикерләрен язма рәвештә тәкъдим итәләр.

Тәрбия эше буенча совет әгъзаларының язма рәвештә кергән фикерләрен гомумиләштерү һәм читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгару тәрбия эше буенча совет секретаре тарафыннан башкарыла.

Әгәр тәрбия эше буенча совет әгъзаларының өчтән икесе билгеләнгән вакытта үз фикерләрен язма формада тапшырган булса, тәрбия эше буенча совет карары кабул ителгән дип санала.

Карар тәрбия эше буенча  овет әгъзаларының күпчелек тавышлары белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда тәрбия эше буенча совет рәисе тавышы хәлиткеч була.

Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тәрбия эше буенча совет әгъзаларының язма фикерләрен кушып беркетмә төзелә, ул секретарь тарафыннан имзалана һәм рәис тарафыннан раслана.

## 6. Тәрбия эше буенча совет эшчәнлеген тәэмин итү

6.1. Тәрбия эше буенча совет эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүматианалитик тәэмин итүне Татарстан Республикасында балалар һәм

яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте төбәк бүлекчәсенең җирле бүлеге башкара.

6.2. Тәрбия эше буенча совет карарлары тәрбия эше буенча совет әгъзалары өчен мәҗбүри булып тора.

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының карарына
2 нче кушымта
15.02.2024
6

**Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтен һәм балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне үстерү, тәрбия эше буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карамагындагы совет составы**

| | |
|---|---|
| Нуриев Р.М. | Алабуга муниципаль районы Башлыгы, тәрбия эше буенча совет рәисе |
| Курамшин Н.Д. | Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль үсеш буенча), тәрбия эше буенча совет рәисе урынбасары |
| Павлова Е.Ю. | Алабуга районының «Беренчеләр хәрәкәте» җирле бүлекчәсе советы рәисе, тәрбия эше буенча совет секретаре |

**Совет әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Балобанова А.С. | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазифаларын башкаручы |
| Смирнов И.В. | Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы мөдире |